| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«7» май 2025г. г. Альметьевск № 359

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең Контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 89 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 103 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 136 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 166 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 186 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 296 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 333 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы

сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль – хисап палатасы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторына, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибендә һәм шартларында:

1.1.1. 1 бүлектә:

а) 3 пунктның беренче абзацында «2,8217» санын «3,1744» санына алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында «1,1411» санын «1,3566» санына алмаштырырга;

в) 5 пунктның беренче абзацында «1,6411» санын «1,8567» санына алмаштырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «1,350» санын «1,5425» санына алмаштырырга;

д) 6.1 пунктының беренче абзацында «1,1053» саннарын «1,2772» саннарына алмаштырырга;

1.1.2. 2 өлешнең 8 пункты 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент», «биләнгән» сүзен «биләгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда)

| «Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 46 167 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 42 628 |
| Район Советы Аппараты җитәкчесе | 42 628 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 41 859 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 41 705 |
| Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 38 781 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 37 857 |
| Идарә җитәкчесе, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 31 702 |
| Идарә җитәкчесе урынбасары, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире) урынбасары, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 26 162 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 26 162 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек җитәкчесе | 26 162 |
| Сектор мөдире | 24 315 |
| Баш белгеч | 23 392 |
| Әйдәп баручы белгеч | 22 007 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 19 698» |

1.3.კарарга 3 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары, сайланулы вазыйфаи затларны айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(сумнарда)

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 46 796 |
| Башлыкның беренче урынбасары, башлык урынбасары | 42 115 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 42 115 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 37 855 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 31 699» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Туманова Г.П.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Р.Е. Әфләтунова

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА